СОВЕТ
ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

с. Шланга

2023 елның 04 мае 26/4

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында.

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 2020 елның 15 июнендәге 51/4 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә” 3 пунктның 2 абзацында, 4, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацында, 11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Раиса)»сүзләре белән алыштырып үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге сайтында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы: И.И.Якупов